КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 20 май г.Казань № 341

Амбулатор шартларда диспансер күзәтүендәге «хроник вируслы С гепатиты» диагнозлы затларны вируска каршы дару препаратлары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәламәтлек саклау системасын үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 26 декабрендәге 1640 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу акарарга теркәлгән Амбулатор шартларда диспансер күзәтүендәге «хроник вируслы С гепатиты» диагнозлы затларны вируска каршы дару препаратлары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 20 май, 341 нче
карары белән расланды

Амбулатор шартларда диспансер күзәтүендәге «хроник вируслы С гепатиты» диагнозлы затларны вируска каршы дару препаратлары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип амбулатор шартларда диспансер күзәтүендәге «хроник вируслы С гепатиты» диагнозлы затларны (алга таба – «хроник вируслы С гепатиты» диагнозлы затлар) вируска каршы дару препаратлары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибе механизмын билгели.

2. Хроник вируслы С гепатиты булганда өлкәннәргә медицина ярдәме күрсәтү стандарты нигезендә «Хроник вируслы С гепатиты» клиник тәкъдимнамәләре буенча амбулатор шартларда диспансер күзәтүендәге «хроник вируслы С гепатиты» диагнозлы затларны вируска каршы дару препаратлары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән һәм әлеге максатлар өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субсидия (алга таба – шул ук эзлеклелектә бюджет акчасы, субсидия) исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы.

4. Бюджет акчасын тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счет аша гамәлгә ашырыла.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, иң чик финанслау күләмнәре Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына җиткерелгәннән соң, иң чик финанслау күләмнәрен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җиткерә.

6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы:

дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарына таянып, әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә «хроник вируслы С гепатиты» диагнозлы затлар өчен вируска каршы дару препаратлары сатып алуга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзи;

дәүләт контрактлары (шартнамәләр) шартлары нигезендә «хроник вируслы С гепатиты» диагнозлы затлар өчен вируска каршы дару препаратлары сатып алуга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзегән оешмаларга акча күчерә.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә, форма буенча һәм срокларда финанслашу максатларында субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында, шулай ук субсидиядән файдалану нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисаплар урнаштыра.

8. Бюджет акчасын максатчан файдаланмаган өчен Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җавап бирелә.

9. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына субсидиянең калган өлеше Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.